| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2022 Баулы шәһәре № 258

2023 елда Баулы муниципаль
районы муниципаль гомуми белем
бирү оешмаларында укучыларны
бушлай тукландыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, сәламәт туклануны оештыру өлешендә «гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларны тукландыруны оештыру» турында СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү максатларында, шулай ук аерым категориядәге укучыларга карата социаль яклауның өстәмә чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2023 елда бушлай туклану белән тәэмин итәргә:

- Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучы 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаиләләрдән балаларны;

- Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы «Семья» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» ДКУ балаларын;

- Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы инвалид балалар.

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2023 елда җирле бюджетны үтәү барышында түләүсез тукмлануны тәэмин итү буенча ташламалар бирү чараларына чыгымнарны каплауга финанс чаралары табарга.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Д.З. Ганиевага, «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2021 елның 16 августындагы 1342 номерлы карары һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә, Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучы 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында мәгълүматны җиткерүне (урнаштыруны) тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров